Татарстан китап нәшрияты
1962


ӘХМӘТ
ИСХАК



# БЕЗНЕҢ ИШЕК АЛДЫНДА

Әхмәт Исхак

# БЕЗНЕҢ ИШЕК АЛДЫНДА



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1962

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 3773

## ЭЧТӘЛЕК

әхетле балалар . . . . . . . . . . . 3
Минем илем . . . . . . . . . . . . 5
Ленинчылар . . . . . . . . . . . . 7
Самолет очты . . . . . . . . . . . 8
Төп законы илемнең . . . . . . . . 10
Безнең урам . . . . . . . . . . . 11
Пионерларның поход җыры . . . . . 13
Безнең ишек алдында . . . . . . . . 14
Үчак янында . . . . . . . . . . . 16
Ана . . . . . . . . . . . . . . . 18
Укытучы . . . . . . . . . . . . . 20
Безнең әби . . . . . . . . . . . . 20
Бала белән сыерчык . . . . . . . . 21
Безнең отряд . . . . . . . . . . . 23
Эш һәм ял . . . . . . . . . . . . 24
Начар гадәте бар . . . . . . . . . 26
Гали белән Вәли . . . . . . . . . 27
Сәгать янында . . . . . . . . . . 29
Рәшит . . . . . . . . . . . . . . 29
Тыныш билгеләренең зары . . . . . 31
Әхмәт белән Рәхмәт . . . . . . . . 33
Ябышма алай артка . . . . . . . . 35
Миләүшә . . . . . . . . . . . . . 38
Чишмә . . . . . . . . . . . . . . 39
Беренче рәхмәт . . . . . . . . . . 39
Нәфисә . . . . . . . . . . . . . . 41
Минем әтәчем . . . . . . . . . . . 41
Кәккүк . . . . . . . . . . . . . . 42
Безнең Гали . . . . . . . . . . . 42
Карт имән белән яшь егет . . . . . 43
Балта ничек үзенә сап ясаган . . . 44
Сөмбелә . . . . . . . . . . . . . 46
Охшаш сүзләр дәфтәре . . . . . . . 47
Сабит һәм хыял турында . . . . . . 50
Аучы . . . . . . . . . . . . . . . 54
Ташбака . . . . . . . . . . . . . 57
Ярлы жире . . . . . . . . . . . . 61

*КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН*

*Ахмед Исхак*

НА НАШЕМ ДВОРЕ

(на татарском языке)

Редакторы *Х. Камалов*
Художниклары *С. Кульбака, Ю. Лысогорский*
Художество редакторы *Б. М. Альменов*
Техник редакторы *З. А. Ибраһимова*
Корректорлары *И. Х. Уразова, А. Ш. Зарипова*

Производствога бирелде 17/III-62 ел. Басарга кул куелды 21/VIII-62 ел. Кәгазь форматы 70x92¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 4,19. Басма табак 4(4,68). Тираж 5000 экз. Заказ № Г-505. Бәясе 15 тиен.

Татарстан Культура Министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды.
Казан, Бауман урамы, 19, 1962 ел.





### БӘХЕТЛЕ БАЛАЛАР

Без ирекле илнең балалары —
Аның сөйгән кыз һәм уллары.
Балкып ята безнең алдыбызда
Киләчәкнең якты юллары.

Үстерә безне
Иркәләп, сөеп
Ватаныбыз — туган әнкәбез.
Без аңарга
Бөтенебез
Чын күңелдән рәхмәт әйтәбез!

Саф һавасын сулап туган илнең,
Без йөрибез урман, кырларда.
Шат тавышы азат балачакның
Яңгырап тора безнең җырларда.

Үстерә безне
Бәхетле итеп
Ватаныбыз — туган әнкәбез.
Без аңарга
Бөтенебез
Чын күңелдән рәхмәт әйтәбез!

Ял итәбез җәен лагерьларда,
Зур елгалар буйлап йөзәбез.
Без йөрибез кышын чаңгыларда, —
Без чыныгып шулай үсәбез.

Үстерә безне
Тазалар итеп
Ватаныбыз — туган әнкәбез.
Без аңарга
Бөтенебез
Чын күңелдән рәхмәт әйтәбез!

Хәзерләнеп шаулы мәктәпләрдә
Белемнәрнең серен чишәргә,
Өйрәнәбез бөтен туган илне
Коммунизм йорты итәргә.

Үстерә безне
Батырлар итеп
Ватаныбыз — туган әнкәбез.
Без аңарга
Бөтенебез
Чын күңелдән рәхмәт әйтәбез!





## МИНЕМ ИЛЕМ

Без мәктәпкә барабыз
Шыгырдатып ак карны.
Нинди матур, карагыз
Безнең туган якларны!
Бездә инде кыш җиткән,
Юлчылар чана җиккән,
Елгалар, күлләр туңган,
Кешеләр йөри туннан.


Минем бар дустым — Рөстәм,
Еракта — көньягында.
Ул шунда туып-үскән,
Шаулы Каспий янында.
Кичә шуннан хат алдым,
Укыгач хәйран калдым:
Җылы әле, ди, бездә,
Коенам, ди, диңгездә.

Менә нинди зур минем
Сөекле туган илем!

Кичә кич без бер чыгыш
Тыңладык Сахалиннан.
— Бездә инде күптән кыш, —
Диде бер апа аннан.
Эш ләкин кышта түгел,
Якшәмбе, ди ул, бүген.

Ә бездә тик шимбә ич, —
Анда — иртә, бездә — кич!

Минем абый хезмәттә
Совет Армиясендә.
Сакта тора ул анда
Киң Амур тирәсендә.
Ул кайтты ял итәргә,
Кунак булып китәргә.
Ун көн кайттым, ди, бире,
Ун көн кайтам, ди, кире.



Менә нинди зур минем
Сөекле туган илем!

Кирәк булса сиңа кыш
Әгәр җәй уртасында,
Төньягына тот та оч,
Табарсың кышны шунда.
Кем кышын җәй сагына,
Очсын ул көньягына.
Бер үк вакыт бар бездә
Җәй дә, кыш та, яз, көз дә.



Үсә күккә ыргылып
Төньягының нараты.
Җиргә төшкән сыгылып
Көньякның винограды.
Дингез, дисәң, күп диңгез,
Теләсәң кайсында йөз.
Теләсәң, йөз күлләрдә,
Теләсәң, йөр чүлләрдә.

Менә нинди зур минем
Сөекле туган илем!



## ЛЕНИНЧЫЛАР

Яши төрле халыклар
Төрле-төрле илләрдә,
Алар бар да сөйләшә
Төрле-төрле телләрдә.

Тик кай телдә сөйләшсә дә
Халыклары дөньяның,
Бер үк төсле һәммәсе дә
Әйтәләр исемен аның:

— Ленин! — диләр немецчә дә,
— Ленин! — диләр русча да,
Кытайча да, инглизчә дә,
Финчә дә, французча да.

Кемнәр яши җир йөзендә
Намуслы хезмәт белән,
Искә ала һәммәсе дә
Аны зур хөрмәт белән.

Искә алалар сөеп:
— Ул — безнең Ильич! — диеп.

Ул өйрәтте халыкларга
Irекне ничек яуларга.
Аның юлыннан барып,
Бәхет тапты күп халык.
Кем, барып Ленин юлыннан,
Көрәшә хаклык өчен
Һәм, артык күреп җаныннан,
Кайгырта халык эшен,
Кем курыкмый бернидән дә,
Кирәк чакта, үлемнән дә,
Кызганмыйча бөтен көчен,
Үтка керә шул эш өчен, —
Аны кешеләр:
— Ленинчы! — диләр.

Җир йөзендә ленинчылар
Күп миллионнар инде алар!


Җирдә хаклык җиңсен өчен
Көрәшә алар бар да.
Күп аларның сафларында
Яшьләр дә һәм картлар да;
Көрәшләрдә һәрвакытта
Бара алар иң алда!

Үсәләр алмаштырырга
Киләчәктә аларны
Җирдә иң яшь ленинчылар
Совет пионерлары.

Үсә алар хәзерләнеп,
Көрәшләрдә Ленин кебек
Кыю, батыр булырга,
Барып Ленинның юлыннан,
Дөньяда тиңе булмаган
Матур тормыш корырга.

Сөеп үстерә аларны
Һәм кадерле ил шуңар.
Алар безнең өметебез —
Булачак ленинчылар!

## САМОЛЕТ ОЧТЫ



Самолет очты биектән,
Яңгыратып һаваны.
Матурлыгына сокланып,
Карап калды ул аны.

Ал йолдызлы корыч кошта
Әткәсе оча аның,
Кошлар җитмәс биеклеккә
Күтәреп илнең данын.

Самолет, шаулап, еракка
Алып китте уйларын,
Шундый иркен, тын һавада
Очасы килде аның.

Уйланды ул, аяз күктәй
Зәңгәр күзләрен йомып,
Һәм калды баскан җирендә
Татлы хыялга чумып...

* * *

Менә ул алсу йолдызлы
Зур корыч кошта инде
Күтәрелә югарыга,
Аста калдырып җирне.





Әткәсе калды озатып,
Сәламләп башын иеп:
— Батыр бул, кызым, курыкма!
Алга бар туры! — диеп.

Ә җирдә ята җәелеп
Якты күлләр, елгалар,
Шәһәрләр, кырлар, авыллар...
Шундый матурлар алар!

Ул оча карап шуларны,
Уйларын көчкә җыеп,
Күтәрелгән саен җирнең
Якынайганын тоеп.


Ул үтә, мәгърур елмаеп,
Данлы илнең чигеннән,
Чит илдәге туганнарга
Сәлам әйтеп иленнән.

Ул илтә ерак илләргә
Батыр халкының данын,
Һәм кайта аннан, сагынып,
Сөекле илгә тагын...

* * *

Ул оча әле һавада
Хыялда гына бүген,
Ләкин бу хыялы аның
Чынлыктан ерак түгел:

Ул үсәр, эшкә ашырыр
Үзенең бу хыялын.
Хыялны эшкә ашыручы
Туган иле бар аның!



Зак. 505 — 2

## ТӨП ЗАКОНЫ ИЛЕМНЕҢ

Гади китап ята минем алда.
Һәр ачканда ләкин мин аны
Дулкынланып ачам, ачкан кебек
Тиңдәшсез бер яңа дөньяны.

Төп Законы минем илемнең ул.
Ул законның һәрбер юлында
Мин җыр кебек матур сүзләр укыйм
Ирек, бәхет, дуслык турында.

Күрәм анда батыр халкымның мин
Көрәш белән үткән юлларын,
Бүгенгенең шат һәм мул тормышын,
Киләчәкнең якты нурларын.


Алган саен кулга горурланып
Һәм сокланып карыйм мин аңа:
Чын бәхетнең нинди икәнлеген
Күрсәтә ул бөтен дөньяга!

Мәктәпләрдә аны дәрес итеп
Өйрәнәләр бездә балалар,
Халыклары бөтен җир шарының
Аннан үрнәк һәм көч алалар.

Юк, түгел ул гади китап кына!
Алган саен кулга мин аны,
Дулкынланып ачам, ачкан кебек
Өр-яңа бер матур дөньяны!



## БЕЗНЕҢ УРАМ



Бу — безнең урам,
Мин шунда торам.
Тукай урамы, —
Ди һәркем аны.

Тукай абый ул
Зур шагыйрь булган.
Бик күп шигырьләр
Язып калдырган.

Бар аның тагын
Матур җырлары.
Мин бик яратып
Җырлыйм шуларны.

Ә ул яшәгән
Иске Казанда,
Патша һәм байлар
Булган заманда.

Ул вакытларда
Безнең бу урам
Бер хатын патша
Исемендә булган.

Булган ул җәен
Тузан оясы,
Көзен һәм язын —
Пычрак һәм сасы.

Тик пошынмаган
Байлар пычракка.
Йөргәннәр чөнки
Һәрвакыт атта.

Бөтен азапны
Эшчеләр күргән,
Ерып пычракны
Эшчеләр йөргән.

Булган ул чакта
Зур йортлар монда.
Тик алар булган
Байлар кулында.

Байлар торганнар
Өске катларда,
Ярлылар — аста
Яки подвалда.

Ике бүлектән
Торган трамвай да:
Арты — ярлыга,
Ә алды — байга.

Кем киган булса
Яхшы, шәп кием,
Барган ал якта,
Түләп биш тиен.

Кем дә кем кигән
Ярлырак кием,
Барган ул артта,
Түләп өч тиен.

Утыр, янәсе,
Үз урыныңа,
Исең кермәсен
Бай борынына!..

Докторлар да тик
Караган байны.
Тилмереп үлгән
Өендә ярлы.

Бушлай дәвалау
Ул чакта кайда!
Ярдәмсез үлгән
Бөек Тукай да!

Торган чат саен
Чиркәү һәм мәчет,
Тирә-ягына
Дошманлык чәчеп.

Мактаган алар
Бар да үз динен,
Агуланганнар
Халыкның миен.

Теләп аерырга
Татардан русны,
Күрсәткән алар
Дошман дип дусны.

Кайда ул чакта
Кино һәм клублар!
Янган бар җирдә
Тик сукыр утлар...

Ә хәзер чыксаң
Безнең урамга,
Бөтен җир чумган
Якты нурларга.

Бөтен җиренә
Җәелгән асфальт.
Карарга матур,
Йөрергә рәхәт!

Үтсәң күз салып
Буйдан-буйгача,
Бар җирдә мәктәп,
Ясле һәм бакча.



Көннән-көн арта
Зур йортлар монда.
Барысы да алар
Халык кулында.

Яшиләр бергә
Татар һәм руслар.

Нинди халык бар,
Һәммәсе дуслар!

Бик якын шуңа
Миңа бу урам.
Мин шунда тудым
Һәм шунда торам!

### ПИОНЕРЛАРНЫҢ ПОХОД ҖЫРЫ

Әйдә, әйдә алга, яшь пионерлар!
Зур җиңүләр көтәләр безне алда.
Яңгырасын шатлыклы, дәртле җырлар
Урманнарда, тауларда, киң кырларда!

Туган илне өйрәнергә
Без походка барабыз.
Безне яңа җиңүләргә
Чакыра Ватан-анабыз.

Безнең өчен барлык юллар ачылган,
Хуҗалары без киләчәк көннәрнең.
Үтеп җирнең өстеннән һәм астыннан,
Өйрәник без табигатьнең серләрен!

Туган илне өйрәнергә
Без походка барабыз.
Безне яңа җиңүләргә
Чакыра Ватан-анабыз.

Туган илебез сөя безне иркәләп
Һәм үстерә җылы, киң кочагында.
Табып яңа байлыкларны бергәләп,
Арттырыйк без аның көчен тагын да!

Туган илне өйрәнергә
Без походка барабыз.
Безне яңа җиңүләргә
Чакыра Ватан-анабыз.

Без барабыз тагы да якты көннәргә,
Зур җиңүләр көтәләр безне алда.
Хәзерләнеп алдагы көрәшләргә,
Чыныксыннар буыннар походларда!

Туган илне өйрәнергә
Без походка барабыз.
Безне яңа җиңүләргә
Чакыра Ватан-анабыз.

### БЕЗНЕҢ ИШЕК АЛДЫНДА

Безнең ишек алдында —
Алты малай, ике кыз:
Алсу, Коля, өч Марат,
Әдип, Фәрит һәм Йолдыз.

Утырганда җыелып
Беркөн ишек алдында,
Сөйләштеләр балалар
Бик зур бер эш хакында.

Ә сүз башланды болай:
Ничектер чыгып уңай,
Беренчедә укучы,
Иң нәни малай Әдип
Сорады: — Тынычлык өчен
Нигә көрәшәләр? — дип.

Коля әйтте (чөнки ул
Арада иң зурысы):
— Булдырмас өчен, — диде, —
Бер җирдә дә сугышны!

Бүлдереп аның сүзен,
Өстәде шунда Фәрит:
— Ә сугыш ул, беләсең,
Бик куркыныч нәрсә бит!

Никадәр зыян китерә,
Күпме кешене үтерә!


— Ә минем әнием тора, —
Дип куйды Йолдыз шунда, —
Сугышны булдырмас өчен,
Тынычлык вахтасында!

Әдип әйтте: — Минем әти
Көн дә ике норма үти!

Бик дәртләнеп кенә шунда
Маратларның олысы
Әйтте: — Әгәр дә фашистлар
Башласалар сугышны,
Икенче көнне үк иртән
Мин ирекле булып китәм!

Алсу әйтте: — Анысы,
Башласалар сугышны,
Туган ил өчен көрәшү —
Һәммәбезнең бурычы!
Ә син менә әйт шуны:
Сугыш башлангач түгел,
Ә аны булдырмас өчен
Нәрсә эшләргә бүген?!





Марат әйтте: — Син мине
Эшләми дип беләмсең?
Ә мин инде үстердем
Никадәр ак күгәрчен!
Алар очкан чагында,
Бөтен кеше сокланып,
Тынычлык өчен көрәшкә
Тормыймыни рухланып?!

Алсу әйтте: — Әллә мин
Бернәрсә дә эшләмим?
Гел әнигә булышам,
Бар нәрсәне юышам.
Өйдә бик арып китеп,
Эштә бирешмәсен дим.
Борчылмыйча өй өчен
Тынычлап эшләсен дим!

— Ә беркөн без, — диде
Йолдыз, —
Өченчедән унике кыз
Тынычлыкка чакырып,
Җырладык радиодан.
Эти әйтә: — Шәп чыкты, — ди
Ул өйдә тыңлап торган.

Коля әйтте: — Үткән ел без
Дүртенче класста һәммәбез
Металл ватыгы җыйдык.
Мәктәпнең ишек алдына
Тау хәтле металл өйдек.
Беләсезме, металл бит
Ныгыта ул илне бик!

Сүзсез торган нәни Марат
Әйтте шунда түбән карап:
— Ә мин әлегә хәтле
Эшләмәдем берни дә.
Ләкин тынычлык җиңсен дип,
Телим һәрвакыт мин дә.

Коля әйтте: — Ә син менә
Утырма тик теләп кенә!

Алсу әйтте: — Бик дөрес,
Теләп кенә булмый эш.

Мондый эштә һәркем бергә
Тиеш бик нык көрәшергә!..

Шулай сөйләшә торгач,
Шактый ук вакыт үтте.
Дәрес хәзерләргә өйгә
Керергә вакыт җитте.

Һәммәсе дә өйләренә
Таралды шунда алар...
Безнең ишек алдында
Менә нинди балалар!

## УЧАК ЯНЫНДА

Бер ата һәм бер ананың
Балалары кебек,
Алтын учак янына без
Утырдык тезелеп.

Сирпеп күккә очкыннарын,
Яна безнең учак.
Без уйладык күптән янган
Бер учакны шул чак.

Соргылт төтен хәтерләтә
Күзгә Урал төнен.
Павлик Морозов турында
Сөйләштек без бүген.

Күреп булмый Идел өстен —
Йөзә аксыл томан.
Килеп баса күз алдына
Кичке салкын урман.

Алсулатып агачларны,
Учак яна анда.
Павлик сөйли. Иптәшләре
Тыңлый, алмый тын да.

— Күрмәделәр алар мине,
Ә мин тордым күреп:
Яшерделәр мылтык алар,
Чыпта белән төреп.

— Ух, кулаклар!..—Кысты тешен
Балаларның берсе. —
Тели алар җимерергә
Безнең бөек эшне.

Тузгытырга бандитларны,
Эх, оясы белән!!
Павлик әйтте: — Мин бүген үк
Сельсоветка керәм...





Учак кабызмаган алар
Күңел ачар өчен —
Кайгыртканнар пионерлар
Шулай колхоз эшен.

Колхозларның дошманнары
Үтергәннәр аны.
Халык эше өчен аккан
Яшь Павликның каны...

Ул юк инде!.. Ләкин безгә
Тоелып китә шунда —
Җырлый кебек учак җырын
Безнең белән ул да:

— Ян, учак, ян,
Яктырак ян,
Ян сүнмичә бер дә, —
Янган төсле көрәш уты
Безнең күңелләрдә!..

Без җырлыйбыз. Күз алдына
Килеп баса шул чак
Ерак Урал урманында
Ул кабызган учак.

Ант шикелле булып шунда
Яңгырый безнең җырлар:
— Без булырбыз Павлик кебек
Батыр пионерлар!

Зак. 505—3

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 3773



## АНА

Моңаеп һәм туңып
Киң елга акканда,
Тын ярлар беренче
Боз белән катканда,

Партизан отряды
Шәһәрне калдырды;
Акларның гаскәре
Шәһәргә агылды.

Кучәргә җыенып
Һөҗүмгә тагын да,
Тупланды отрядлар
Шәһәрнең янында.

Үч алды халыктан
Дошманнар котырып, —
Тутырып төрмәгә,
Җәзалап, үтереп...



Күзләрдә дошманга
Ачулы ут яна.
Тоткыннар сафында
Күренә бер ана.

Палачлар ананы
Төрмәгә илтәләр.
Ул сөя кулдагы
Баласын иркәләп.

Тирәдә кешеләр
Кызганып карыйлар.
Һәм канга сусаган
Дошманны каргыйлар.

Ә ана баласын
Күтәргән кочаклап.
Җиңүче шикелле
Бара ул төз атлап.

Ачтылар сакчылар
Капкасын төрмәнең.
Күрделәр ананың
Куркусыз кергәнен.

Туңдыра баланы
Төрмәнең салкыны.
Җылыта тик аны
Ананың ялкыны.

Шул төндә ананы
«Хөкем» дә иттеләр.
Таң белән атарга
Алып та киттеләр.

Тын төнне уздырды
Үлемен ул көтеп.
Калдырды балага
Бер язу беркетеп:

«Әгәр, балам, исән калсаң
Дошман кулыннан,
Курыкмыйча алга атла
Әнкәң юлыннан.

Хәтерли дә алмассың син
Әнкәңнең төсен.
Тик онытма күрмә аның
Көрәшкән эшен.

Син үсәрсең, чәчәк кебек,
Бәбкәм, бу җирдә —
Без кан түгеп, сугышып алган
Ирекле илдә.

Ана булыр сиңа — илең,
Ә син аңа — ул.
Сөй син аны әнкәң итеп,
Турылыклы бул!

Әгәр дошман кулын сузса
Таларга аны,
Искә төшер шул ил өчен
Үлгән анаңны.

Таптатма ул дошманнардан
Әнкәңнең кабрен.
Үлгән чакта васыятем
Шул сиңа, бәгърем!»

## УКЫТУЧЫ

Үтәр көннәр, үтәр айлар,
Үтәрләр бик күп еллар,
Күп исемнәр истән чыгар,
Күп эшләр онтылырлар,

Ләкин гомерең буенча
Кайда гына булсаң да,
Туган-үскән җирләреңнән
Нинди ерак торсаң да,

Булсаң да син нинди эштә, —
Яз, җәен, көзен, кышын, —
Булыр берәү синең белән:
Ул — синең укытучың!

Ул — сиңа хәреф өйрәткән
Һәм белем биргән кеше;
Яхшылык теләп йөрәктән,
Тырышып йөргән кеше.

Самолет рулен тотсаң да,
Тракторлар йөртсәң дә,
Мәктәпләр, йортлар салсаң да,
Корычлар эретсәң дә,

Тынычта да, сугышта да,
Ни эшкә тотынсаң да,
Сиңа биргән белем аша
Ул булыр синең янда.

Синең һәрбер уңышыңда
Аның да бар өлеше.
Ул шуларның барына да
Сине өйрәткән кеше.

Хөрмәтләп искә алырсың
Син аны киләчәктә.
Димәк, хөрмәтлә бүген дә —
Укыганда мәктәптә!

## БЕЗНЕҢ ӘБИ

Безнең әби бик карт инде,
Яше җиткән җитмешкә.
Чәчләренең һәр бөртеге
Манган төсле көмешкә.

Ә шулай да үзе әле
Бернигә дә бирешми:
Пенсиягә чыкса да ул,
Мәктәбендә гел эшли.

Кырык ел инде һаман да
Балалар укыта анда.



Шул эше өстенә тагын,
Булса да ул инде карт,
Йөри һаман райсоветка —
Ул бит анда депутат!

Вакыт таба шул арада
Безнең белән булырга да.
Без утырсак янында,
Сөйли безгә барын да:

Ярты гомере узган
Авыр заманда аның.
Кичергән ул башыннан
Көрәшнең бар юлларын.

Укыткан ул балалар
Үзебезнең бистәдә.
Эшчеләргә аң-белем
Бирә булган кичләрдә.

Бабай белән ничә кат
Маёвкада булган ул.
Октябрьда иң алда
Байрак тотып барган ул.

Ул сөйләргә тотынса,
Без тын алмый торабыз.
Туктамаса ярар иде! —
Дигән күк утырабыз.

Беркөн ул безгә сөйләде
Башкалада булганын,
Ильич белән озак кына
Сөйләшеп утырганын.

Бәхетле безнең әби!
Бар кеше дә шулай ди.

Аны белмәгән кеше
Һич юк безнең урамда.
Картлар, яшьләр баш иеп
Сәламли аны бар да.

Узган һәр кеше аңа
Карап кала сокланып.
Аның янында булсам,
Барам мин горурланып.

Мин бик шатланыр идем
Аның шикелле булсам:
Гомеремне аның кебек
Матур итеп уздырсам!

## БАЛА БЕЛӘН СЫЕРЧЫК

Сөйлә әле, сыерчык,
Кайдан кайттың син очып?
Кышын кайларда йөрдең,
Кайда нәрсәләр күрдең?

— Мин булдым чит илләрдә,
Моннан ерак җирләрдә,



Диңгезләр артында ук,
Кайда кыш, салкыннар юк.
Ләкин анда кешеләр
Коллар кебек яшиләр.
Бәхетле түгел анда
Кечкенә балалар да:
Саргайган яңаклары,
Һаман ач тамаклары,
Уйнамыйлар, көлмиләр,
Мәктәпләргә йөрмиләр,
Мондагы күк бәхетле
Шат тормышны белмиләр.

— Сөйлә әле, сыерчык,
Бездән киткәчтен очып,
Ул җирләрдә торганда
Ни эшлисең син анда?

— Мин анда һич тик тормыйм,
Уйныйм, очам һәм җырлыйм.
Җырларымда һәр чакта
Сөйлим мин сезнең хакта.

Тик ятмыйлар алар да,
Көрәшәләр һаман да
Ирекле булу өчен,
Шат тормыш кору өчен.

Алар сезне беләләр,
Сезнең илне сөяләр:
«Без дә тиздән алар күк
Шат булырбыз!» — дияләр.



## БЕЗНЕҢ ОТРЯД

Зур түгел безнең мәктәп,
Нык ләкин безнең отряд.
Санда түгел чөнки эш,
Бергәлектә бөтен көч.
Һәрвакыт без отрядта
Кай эшкә керешсәк тә,
Бергәләп керешәбез,
Теләккә ирешәбез.
Шунлыктан безнең хакта
Сөйлиләр тирә-якта:
Керешсә әгәр отряд,
Чыга, диләр, аннан рәт!

Без беркөн карар бирдек:
Отличник булыйк дидек,
Түгел тик берәм-берәм,
Ә бөтен отряд белән.
Без бергәләп керештек,
Ел буенча тырыштык,
Бер-беребезгә булыштык
Һәм әйткәнгә ирештек.
Шуңа да безнең хакта
Сөйлиләр тирә-якта:
Керешсә әгәр отряд,
Чыга, диләр, аннан рәт!

Без тагын карар бирдек:
Тирәсендә мәктәпнең —
Ясыйбыз бакча дидек,
Көче белән отрядның.
Агач утырттык бергә,
Бергә бизәдек гөлгә,
Бергәләп койма кордык
Һәм зур бакчалы булдык.
Һәм тагын безнең хакта
Сөйлиләр тирә-якта:
Керешсә әгәр отряд,
Чыга, диләр, аннан рәт!

Язгы чәчү алдыннан
Без көл җыйдык авылдан.
Җәй көне чыктык кырга
Утауда булышырга.
Уракта җыйдык башак —
Бергәләп, өмә ясап.
Тагын да безнең хакта
Сөйлиләр тирә-якта:
Керешсә әгәр отряд,
Чыга, диләр, аннан рәт!

Без тату, дус яшибез,
Укыйбыз һәм эшлибез.
Бергәләшеп уйлыйбыз,
Бергәләшеп уйныйбыз.
Кайгыртмый бездә бер дә
Үзен генә беркем дә.
Соклана безгә зурлар,
Без тырыш пионерлар.
Һәрвакыт безнең хакта
Сөйлиләр тирә-якта:
Керешсә әгәр отряд,
Чыга, диләр, аннан рәт!

### ЭШ ҺӘМ ЯЛ



Кайтуы белән дәрестән,
Булатларга керде Рөстәм.
— Әй син! — диде ул аңарга, —
Тиз чыгасыңмы уйнарга?

Булат төймә тага иде:
— Мин бераздан чыгам, — диде. —
Әле төймә тагасым бар,
Аннан утын ярасым бар...

Рөстәм йөгерде Илдарга,
Чакырды аны уйнарга.

— Әле чыкмыйм, — диде Илдар, —
Минем чана ясыйсым бар.
Чана сорый энем Галӣ.
Ул, беләсең, үзе нәни!

Рөстәм керде Әхтәмнәргә,
Аны уенга өндәргә.

Әхтәмнең әнисе әйтте:
— Ул тагын мәктәпкә китте.
Ул һәр шимбә мәктәптә
Эшли физтүгәрәктә!



Гаталарга керсә, Гата
Электрны төзәтеп ята.
— Әле бик тиз чыгалмыйм, — ди.—
Яктыда эшләп калыйм, — ди.





Сәлимгә керсә, анысы
Кайрап ята зур бер кайчы.
— Тотынганчы дәресләргә,
Кирәк, — ди, — бераз эшләргә.
Хәзер кисәм мин калай, — ди. —
Мотор ясыйм мин, малай,— ди.

«Кыз кеше булса да, шунда,
Уйнарга ярар, дип, ул да!»
Сараларга керде Рөстәм.
Ә ул кайтуга дәрестән,
Тотынган идән юарга.
— Шунсыз чыкмыйм, — ди, —
уйнарга...

Шуннан өйдән өйгә йөреп,
Шактый вакытны уздырып,
Рөстәм бик күңелсез генә
Чыкты да капка төбенә,
«Нишләргә?» — дип, башын кашып,
Шактый торды шунда басып.



Рөстәм тәмам аптырады
Һәм үз-үзеннән сорады:
— Нишләгән соң бу балалар?
Ял итә соң кайчан алар?

Аңламый шул мескен Рөстәм
Алар шулай ял иткәнне,
Дәрестән соң мондый эшләр
Үзләре бер ял икәнне!

Зак. № 505 -4

**НАЧАР ГАДӘТЕ БАР...**

Безнең песи үзе ишек ача белә,
Кирәк чакта ачып чыга, ачып керә.

Мияуламый, ялвармый ул беркемгә дә,
Йөри шулай бер бүлмәдән бер бүлмәгә.

Ачканда ул ача, ләкин яба белми.
Бу турыда уена да аның керми.

Ишек ачык кала бит, дип, исе китми.
Песи бит ул, — моңа аның башы җитми.

* * *

Охшатам мин Сәлимне дә шул песигә:
Ялынмый ул, ялвармый ул бер кешегә.

Теләгәнен үзе эшли һәммәсен дә:
Үзе тага, төшкән булса, төймәсен дә,

Төзәтә ул чанасын да, чаңгысын да,
Ясап куя хәтта радиоалгычын да.

Кыскасы шул — аның эшкә сәләте бар!
Ләкин аның бик начар бер гадәте бар:

Җыеп йөрми артыннан эш коралларын,
Кайда тотса, калдыра ул шунда барын.

Җыю аның уена да хәтта керми,
Һәммәсен дә әниләре җыеп йөри...





**ГАЛИ БЕЛӘН ВӘЛИ**

Гали дә сөя аны,
Вәли дә сөя аны, —
Нәрсәне?
Машинаны.

Әнә җиңел машина
Бара урамнан.
Гали кала озатып,
Күз алмый аннан.

Керә дә ул өенә
Акрын гына атлап,

Машиналар турында
Укый төрле китап.

Ала төрле такталар,
Калай кисәкләре,
Пружиналар, кадаклар,
Сәгать көпчәкләре.

Һәм нәни бер машина
Ясап куя Гали.
Аның ничек йөргәнен
Карап тора Вәли.

Вәли әйтә Галигә:
— Шәп бит чыннан да!
Ә этинең «Победа»сы
Шәбрәк моннан да.

Шофер басса педальгә,
«Выжт!» итеп китә,
Бер минутта мәктәпкә
Барып та җитә.

Ә мин машинада
Йөрергә яратам.

Шуңа да мин мәктәпне
Өч тапкыр уратам.

Төшәм шуннан соң гына.
Ә кайтканда өйгә,
Йөрим ярты сәгатьләп.
Ә йөрмәскә нигә?

Гаражда бит этинең
Машинасы бик күп.
Теләгәнең чакырт, — ди
Миңа ул үзе үк...

Гали әйтә: — Ясыйм, — ди, —
Үскәч, мин аның
Корыда да, суда да
Йөри торганын!

Ышанам мин: Гали үскәч,
Бар нәрсәне дә эшләр,
Үсә ул шуңа өйрәнеп.

Ә менә Вәли нишләр?



## СӘГАТЬ ЯНЫНДА

Тик! Тик! Тик!
Тикелдисең ник?

Синең вакытны
Шулай саныйм бит.
Ә синең вакыт
Күп калмады бик.
Ал китапларың,
Торма болай тик.
Куярга вакыт

Ялкаулыкка чик!
Утырсаң һаман,
Вакытым күп дип,
Дәрес карарга
Өлгермәссең бит!..

Тик! Тик! Тик!
Тик! Тик! Тик!
Вакытың бетте,
Бар, янымнан кит!

## РӘШИТ

Рәшитнең бар белгәне
Химия дә химия.
Шул химия дия-дия
Тәмам теңкәгә тия.

Өстәлендә һәртөрле
Савытлар тулып ята:
Кайсысында нашатырь,
Кайсысында кислота.

Карасаң тәрәз төбенә,
Пробирка да шешә генә.

Мәктәптән кайткач та көн дә
Маташа тәрәз төбендә:

Бер пробирканы ала да,
Аңа нәрсәдер сала да,
Нәрсәдер өстәп шуңа,
Болгата, салып суга.

Шуннан бөтен бүлмәгә
Чыга әллә нинди ис, —

Ишек, тәрәзне ачмыйча,
Чыдап булмый өйдә һич!

— Нишләдең тагын? — дисәң,
— Тәҗрибә ясадым! — ди.
Ә нишләгәнен тикшерсәң,
Үзе берни дә белми.

Кулына ни эләксә,
Шуны салып караган:
Нашатырь да, тоз да, су да,
Бал да, сөт тә калмаган.

Беркөн түгеп кислотасын,
Яндырган яңа пальтосын.
Ә башка дәресләренә
Хәзерләнә тиз-тиз генә.

ке ачып карый да,
ı-моннан сызгалый да,
куеп китапларын,
рибәсен» башлый тагын...

ій күз үтеп китте,
іче чирек бетте.

шунда аның
іен алып кайтты.
іа аның әтисе
і күреп шаккатты:

ін бөтен табельгә
ічле дә икеле!
әсе дә бит боларның
ксезгә мавыгуның
җәсе, билгеле!



## ТЫНЫШ БИЛГЕЛӘРЕНЕҢ ЗАРЫ

Беркөн тыныш билгеләре
Зарландылар үзара:
— Күрергә кирәк, — диделәр, —
Бу Сарага бер чара!

Өтер әйтте: — Ул бит инде
Өченчене бетерде!
Үзе һаман куя белми
Мине, ягъни, Өтерне.

Инде җөмлә беткән була,
Кирәк нокта куярга.
Ә ул, юньсез, мине куя.
Нишлим инде моңарга!

Мин, гомумән, аның белән
Аптырап беттем инде:
Нәрсә куярга белмәсә,
Тота да куя мине...

— Ә мине ул, — диде Эндәш, —
Белми хәтта бар дип тә!
Бер җиргә мине куймаган
Беркөн язган өч биттә!

— Ә сез шуны беләсезме? —
Диде Сорау билгесе. —
Беркөн дәрестә ул мине
Итте адәм көлкесе.

Бөтен җирдә мине куйган,
Уйламый да аз гына,

«Ничек», «нинди», «кайда» дигән
Һәрбер сүзнең артына!..

— Түзә алмыйм, — диде Җәя, —
Артык мин дә аңарга.
Ачканда ул мине ача,
Ә оныта ябарга!..

— Ә мине, — диде Күп Нокта, —
Сибә, кызганмый бер дә.
Кайвакыт дүртәрне куя
Өчне куясы җирдә.

Хәтта Сорау билгеләре
Артына да ул мине
Беркөнне диктант язганда
Өчәрне куйган иде.

Әйтергә кирәк аңарга:
Ул болай уйнамасын.
Күп Нокта, дигәч тә алай,
Бетмәс дип уйламасын!

— Ә беркөнне, — диде Сызык, —
Мине шундый хур итте:
Дөрес торган урынымнан
Кырып кына ыргытты!

— Нигә кырдың? — дип сорагач:
— Алай дөрес булмый, — ди. —
Ноктадан соң бервакыт та
Зур Сызык куелмый, — ди...

— Белми ул кагыйдәләрне, —
Диде Өтерле Нокта. —
Шуңа күрә дөрес куймый
Ул безне бервакыт та!



— Дөрес, — диде Нокта ана, —
Шуңарга да ул надан.
Кирәк Сарага аларны
Өйрәтергә яңадан!

## ӘХМӘТ БЕЛӘН РӘХМӘТ

Әхмәт тормый Рәхмәтсез,
Рәхмәт йөрми Әхмәтсез.

Барган чакта мәктәпкә,
Рәхмәт кирә Әхмәткә.

Кайткан чакта мәктәптән,
Әхмәт калмый Рәхмәттән.

Бергә хәзерли алар
Дәресне,
Бергә эшлиләр алар
Һәр эшне.

Кая барса да алар,
Һаман бергә баралар:
Хәтта китапханәдән
Бер үк китап алалар.

Ничектер бер ялгыз кергән
Рәхмәт китапханәгә.
Ике китап язып биргән
Андагы апа аңа.

Үзе әйткән Рәхмәткә:
— Бусы, — дигән, — Әхмәткә!

Йөргәнгә шулай алар
Һәрвакыт бергә генә,
Балалар да күнеккән
Бергә күрергә генә.

Ялгыз күрсәләр Әхмәтне:
— Кая Рәхмәтең? — диләр.
Ялгыз күрсәләр Рәхмәтне:
— Кая Әхмәтең? — диләр.

Әхмәтнең шатлыгы булса,
Рәхмәт йөри елмаеп.
Рәхмәткә бер кайгы килсә,
Әхмәт йөри моңаеп.

Суык тиеп беркөн Әхмәткә,
Килми торды ун көн мәктәпкә.


Рәхмәт йөрде өч көн кайгырып,
Чак китмәде үзе авырып.

Тапты тагын үзе ул җаен:
Әхмәтләргә йөрде көн саен.

Нинди дәрес үтсәләр
Мәктәптә,
Сөйләп бирде һәммәсен
Әхмәткә.



БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 3773



Алар бергә утырып
Һәр кичне,
Бергә хәзерләделәр
Дәресне.

Шулай артка калмады
Әхмәт тә.

Һәркем шатланды моңа
Мәктәптә.

Мәктәптәге балалар
Сөйлиләр:
— Менә болар, ичмасам,
Дус! — диләр.



## ЯБЫШМА АЛАЙ АРТКА...

Карамыйча буранга,
Гали чыкты урамга.
Киде тимераягын,
Кулга тотты таягын.

Озак кына ул уйнады,
Тротуарларны буйлады.
Бәрелде ул бер кызга,
Егылды үзе бозга.

Аннан ул бер этне күрде,
Аның артыннан йөгерде.
Ега язды бер бабайны,
Аннан нәни бер малайны.

Аннан шуудан туеп,
Таягын читкә куеп,
«Инде нишлим икән? — дип,
Өйгә керим микән?» — дип,
Карап торды урамга,
Карап торды буранга.

Менә бер ат узып бара.
Атка җиккән артлы чана.




Атны бер абый тоткан,
Башын якага тыккан.
Борылмыйча артына,
Җарап бара атына.

Гали моңа бик шатланып,
Тиз-тиз генә шуып барып,
Чана артына тотынды...
Һәм шунда Гали тотылды!

Җарап барса да атына,
Борылмаса да артына,
Абый аны күргән икән,
Ябышканын белгән икән.

Ул сузылып тиз генә
Галинең бүрегенә,
Бүрекне алып кулына,
Җитеп барды үз юлына.

Акырып бөтен урамга,
Тотынды Гали еларга:





— Бүрегемне бир, зинһар, — ди,—
Әнием мине кыйнар, — ди, —
Ябышмам, — ди, — артыңа,
Минем бит башым туңа!..

Бу тавышка хәйран калып,
Җыелды урамга халык.
Кайсы көлеп карый аңа,
Кайберләре ачулана:
— Менә юньсез бала! — диләр.
— Шулай кирәк аңа! — диләр.

Кайсы Галине кызгана:
— Тияр, — диләр, — суык аңа!
Бүреген бәр атып, — диләр, —
Ябышмас ул артык! — диләр.

Теге атта барган абый,
Бүрек тартып алган абый,
Туктатты да атын шунда,
Бөтен халык арасында
Бүрекне Галигә бирде.
Биргән чакта болай диде:

— Кара, акылсыз малай!
Икенче йөрмә алай!
Ябышма алай артка,
Тапталуың бар атка!

Утырып аннан атына,
Карамый тагын артына,
Чыбыркы тотып кулына,
Җитеп барды үз юлына.

Елый-елый менә шунда,
Бөтен халык арасында
Гали калды оялып,
Оялып һәм хурланып,
Уртасында урамның,
Уртасында буранның.

## МИЛӘҮШӘ

Болындагы чәчәкләр
Сөйләшә:
— Бигрәк игътибарсыз кыз
Миләүшә.

Үзе безне ярата
Шулхәтле,
Өзми китми күргән бер
Чәчәкне.

— Бу соң нинди чәчәк? — дип
Тормый ул.
Исемнәрне дә безнең
Белми ул.

Сорасалар әгәр дә
Кешеләр,
Куша безгә коточкыч
Исемнәр.

Гөләп, имеш, аныңча —
Ал чәчәк,
Ә тукранбаш — нииндидер
Бал-чәчәк.

Ә төнбоек, аныңча —
Ак чәчәк,
Чыпчык күзе, имештер,
Вак чәчәк.

«Ах нинди!» дә «Ах матур!» —
Бар сүзе.
Бишенчедә укый бит
Ул үзе!

— Нинди була миләүшә? —
Дип ана
Әйткән иде беркөнне
Бер бала:

— Андый чәчәк барын мин
Белмим, — ди. —
Чәчәк түгел Миләүшә,
Ул — мин! — ди.

Эх, Миләүшә, Миләүшә!
Син яраткан чәчәкләр
Менә ничек сөйләшә!



## ЧИШМӘ

Челтер-челтер чишмә ага,
Көмеш төсле сулары.
Су өстендә җем-җем итә
Көннең алтын нурлары.

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

Безнең чишмә борыла-борыла
Зур инешкә коела.
Идел суы шундый бик күп
Чишмәләрдән җыела.

Тау астында чишмәбез,
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

## БЕРЕНЧЕ РӘХМӘТ

Алсу хәзер зур кыз инде —
Аңа өч тулган.
Алсу бүген абыйсының
Яулыгын юган.

Сабынлаган да яулыкны,
Чиләккә тыгып
Чайкаган һәм элеп куйган,
Тормаган сыгып.



Шатлыктан нәни Алсуның
Күзләре яна:
Рәхмәт әйткән моның өчен
Абыйсы аңа.

Мөмкин түгел шатланмаска:
Бит шундый рәхәт
Чын күңелдән эшләп алган
Беренче рәхмәт!



## НӘФИСӘ

Түтәл сакларга куштылар
Нәфисәгә.
— Тимәсен кош-корт, —
дицеләр, —
Яшелчәгә!

Нәфисә бик тырыш кыз ул —
Торды сакта,
Җәй буена күзен йөртеп
Һәр дүрт якка.

Рәшәткәгә кунса хәтта
Берәр кошчык,
Нәфисәбез чапты шунда,
Чыбык тотып.

Кая инде якын килү
Тавык-чебеш!
Берәр чыпчык күренсә дә,
Куды — көш! көш!

Түтәлләре ышанычлы
Кулда хәзер —
Керә алмый сыерчык та
Монда хәзер.

Шулай итеп, җәй көннәре
Үтеп китте.
Яшелчәне җыяр вакыт
Килеп җитте.

Түтәлләрне әниләре
Тикшерсәләр, —
Кортлап беткән андагы бар
Яшелчәләр!

## МИНЕМ ӘТӘЧЕМ

Минем әтәчем
Бик иртә тора:
Кикрикүк!
Кикрикүк!
Бик матур итеп
Сузып кычкыра:
Кикрикүк!
Кикрикүк!

Очып менә ул
Койма башына:
Кикрикүк!
Кикрикүк!
Һәркем соклана
Аның тавышына:
Кикрикүк!
Кикрикүк!

Ул тирә-якка
Борылып карый:
Кикрикүк!
Кикрикүк!
Кем нәрсә эшли —
Һәммәсен барлый:
Кикрикүк!
Кикрикүк!

Туктап торуны
Ул бер дә белми:
Кикрикүк!
Кикрикүк!
Безне тырышып
Эшләргә өнди:
Кикрикүк!
Кикрикүк!

## КӘККҮК

Җылы яз җиткәч,
Кара урманнан
Кәккүк тавышы
Яңгырый һаман:
Кәккүк!
Кәккүк!

Һич күреп булмый
Үзен якыннан,
Тик тавыш килә
Агач башыннан:
Кәккүк!
Кәккүк!

Башка кошлар күк,
Ул оя кормый,
Үстерми бала,
Җырлый да җырлый:
Кәккүк!
Кәккүк!

Ул чит ояга
Күкәйләр салган,
Эзли шуларны
Моңаеп һаман:
Кәккүк!
Кәккүк!

## БЕЗНЕҢ ГАЛИ

Безнең Гали бигрәк тату әби белән.
Менә әби чакрып аны тәрәзәдән,
Туган көнен котлап, чәчәк бүләк итә,
Гали рәхмәт әйтми генә алып китә.





## КАРТ ИМӘН БЕЛӘН ЯШЬ ЕГЕТ

(Мәсәл)

Үзләренең йортлары тирәсендә
Моннан йөз еллар чамасы элек
Бабасы утырткан имәннең күләгәсендә
Ята иде, ял итеп, яшь кенә бер егет.
Ята торгач карап агачка,
Шундый уй туды егетнең башында:
«Нигә кирәк булган инде картлачка
Утыртырга имән агачы монда?
Нинди файда бар мондый агачтан?
Инде утырткачтан,
Кирәк иде утыртырга алма агачы:
Булыр иде, ичмасам, алмасы,
Ягъни — кешеләргә файдасы...»
Егетнең нәрсә уйлаганын белеп,
Кешеләрчә телгә килеп,

Әйтте аңа, ачуланып, шунда имән:
— Ә нинди файда бар кешеләргә синнән?
Дөрес, мин
Алма бирмим,
Аның каравы мин якын-тирәгә
Биреп торам күләгә.
Бабаң мине утыртты шуның өчен дә.
Ятасың менә син дә
Бабаң утырткан агач күләгәсендә.
Ә үзеңә килсәк,
Синең бит хәтта
Утыртканың юк кечкенә куак та.
Димәк,
Берәүгә дә
Калмас синнән күләгә дә!..

* * *

Бу мәсәлнең морале
Бик үк яңа түгелдер, бәлкем.
Ләкин кайберәүләргә аны
Кабатларга ярый әле һәр көн.

## БАЛТА НИЧЕК ҮЗЕНӘ САП ЯСАГАН

Балта үз хуҗасына
Бик озак хезмәт иткән.
Сабы аның ахырда
Ярылып, бушап беткән.

Хуҗасы кызып кына
Юнып яткан чагында,
Төшә башлаган балта,
Тора алмый сабында.



Телгә килеп беркөнне,
Әйткән ул хуҗасына:
— Минем белән эшләве
Җайсыз бит, хуҗам, сиңа!

Болай булса, безнең эш
Беркөн туктап калачак.
Иске сапны ташла да
Куй син миңа яңа сап!

— Шулай, — дигән хуҗасы, —
Дөреслек бар сүзеңдә.
Уйлый идем мин күптән
Бу турыда үзем дә.

Ләкин син бит, балта дус,
Барсын эшли аласың:
Агачын да кисәсең,
Тактасын да ярасың.

Теләгәндә син үзең
Хәтта йорт та саласың.
Неужели үзеңә
Бер сап ясый алмассың?..

Бу сүзләрне ишеткәч,
Балта, барып урманга,
Кисеп кайткан бер саплык
Һәм керешкән юнарга.

Эшләгән ул шулкадәр
Дәртләнеп һәм тырышып,
Тирә-якка йомычка
Очкындай торган очып!

Баш-башларын кисәргә
Пычкы дусты булышкан.
Тигезләргә ян-янын
Ышкы дусты булышкан.

Сап ясалып бетүгә,
Шкурка белән игәү
Шомартканнар бар җирен
Тырышып шунда икәү.

Яңа сапны шуннан соң
Хуҗасы кулга алып,
Матурлыгына аның
Карап торган сокланып.

— Молодец! — дигән хуҗа,
Балтаның эшен мактап.
Һәм тотынган эшләргә,
Куеп аңа яңа сап.

Һәм әйткән оныгына:
— Шундый тырыш ул менә!
Нинди матур яңа сап
Ясап куйды үзенә!

Син дә, улым, үрнәк ал
Шушы тырыш балтадан:
Үзең эшли алганны
Көтеп ятма башкадан!



## СӨМБЕЛӘ

Дәү инде безнең Сөмбелә,
Бишкә кадәр саный белә:
— Бер,
Ике,
Өч,
Дүрт,
Биш!..
Әнә дөрес саный ич!

— Яле, унга кадәр сана! —
Дигән идек беркөн аңа.
Болай санап китте ул:
— Алты,
Сигез,
Җиде,
Ун!

Аның болай санавына
Сигез бик нык шатланды:
— Җидедән алдарак әйтә
Мине ул! — дип мактанды.

Үз чиратында әйтмәгәч,
Көнләшеп, Җиде:
— Мине ул алтыдан соң ук
Әйтергә тиеш! — диде.

Ә Тугыз чак-чак еламый:
— Мине бөтенләй санамый,
Кирәксез нәрсә кебек,
Калдырды, — ди, — төшереп!..

Карап шунда саннарга,
Болай дидем аларга:
— Өйрәнер ул һәммәгезне
Тиздән дөрес санарга.

Болай санар моннан соң:
Алты,
Җиде,
Сигез,
Тугыз,
Ун!



## ОХШАШ СҮЗЛӘР ДӘФТӘРЕ

*Әйтелеше бер төрле,*
*Мәгънәләре мең төрле*
*Охшаш сүзләр турында*
*Сөйлибез бу урында.*

### Сайлап ал!

Бу чәчәк — **кызыл,**
Ә монысы — **ал.**
Кайсын телисең,
Шуны сайлап **ал!**

### Итекче сүзе

Бусы — тегәрҗеп,
Ә монысы — **без.**
Тегәбез итек
Шулар белән **без.**

### Елак кыз

Елый-елый бу **кыз арган,**
Шуңа битләре **кызарган.**
Күп елаганга **күрә**
Күзе дә начар **күрә.**

### Киңәш

Авыртмасын дисәң, **эч,**
Кайнаган су гына **эч!**

### Баскыч төбендә

Черегән бу **басмагыз,**
Анысына **басмагыз!**

### Эзләп тап!

Кулмәгеңә төшкән **тап,**
Кай җирендә — эзләп **тап!**
Тамызгансың бит **кара.**
Әнә, алдыңа **кара!**

### Кер юганда

Суың суынган, **Алсу!**
Әнә, казаннан **ал су.**
Кайнар суда ю **керне,**
Тиз бетерә ул **керне.**

### Ватык мичкә

Ярарлык бу **мичк**
Ягарга тик **мичкә.**

### Бүленгән төш

Ракета белән очканын
Күргән Рәшит төшендә.
Бүлдерделәр төшемне ди,
Иң кызыклы төшендә!

### Яулык

Зәйнәп азап чигә-**чигә**
Абыена яулык **чигә.**
Ә яулыкның **чит-читен**
Чигүе бигрәк **читен.**
Ул азап чиксә **чикте,**
Ләкин яулыкны **чикте.**
Ә абые **Рәхмәт**
Әйтте аңа **рәхмәт!**

### Печән өстендә

Кибеп беткәнче **чык**
Печән чабарга **чык!**

### Кырын карама!

Утауга карасаң **кырын,**
Чүп басар колхозның **кырын.**

### Учак янында

Сүндермәс өчен **утын,**
Өстә учакка **утын!**

### Кем менә?

Бик текә бу **кыя,**
Менәргә кем **кыя?**
Сукмак та бар, **менә:**
Я, башлап кем менә?

### Кем нишли?

Фәридә бара **суга,**
Галәви кирпеч **суга.**
Миңлекәй печән **чаба,**
Сәлим авылга **чаба.**
Әхмәди утын **яра,**
Хөршидә бәйли **яра.**
Кәримә бодай **ура,**
Әмир кычкыра **«Ура!»**
**Ә Вәли**
Балчык **әвәли.**
Галине чаккан **кычыткан,**
Аның аягы **кычыткан.**
Сабын суза **Галимә:**
Юып бак, ди, **Гали, мә!**
Мәһитап кына бары **тик**
Берни эшләми — тора **тик.**
Ялкауланма, **Мәһитап,**
Син дә бер эш, **Мәһи, тап!**

### Бәйрәм иртәсе

Шундый чиста,
Шундый аяз **күк,**
Бәйрәм өчен
Юып куйган **күк!**

### Киенү бүлмәсендә

Бу бүрек минеке түгел,
Бу — бөтенләй **башка:**
Минем бүрек таман иде,
Ә бу — сыймый **башка!**

### Бүре

Чыгармыйча **өнен** дә,
Посып ята **өнендә.**
Чыгар өчен юк шул бер дә **юнь:**
Этләр белән тулган тирә-**юнь.**

### Сорау

— Әйт әле шуны, **туган,**
Син кайсы елны **туган?**

### Рәхим ит!

Булса карының бик **ач,**
Әнә, суыткычны **ач!**
Бардыр анда пешкән **ит,**
Аша шуны, рәхим **ит!**

### Китек таба

Апа табаның
Бер читен **киткән.**
Әнинең моңа
Кәефе **киткән:**
Бигрәк шәп иде
Шушы **табам!** — ди.
Инде андыйны
Каян **табам?** — ди.

### Кисәтү

Уйнаган чакта
Елама, **яме!**
Югыйсә, китә
Уенның **яме.**

### Ахыргы сүз

Күпме язсаң да,
Булмас, **ахыры,**
Мондый сүзләрнең
Очы, **ахыры!**

---



## САБИТ ҺӘМ ХЫЯЛ ТУРЫНДА

Ярата Сабит
Гел уйланырга,
Уйларга чумып,
Хыялланырга.

Килә, мәсәлән,
Аның башына
Ясау шундый бер
Гаҗәп машина:

Хәрәкәт итсен
Ул бар урында —
Йөзсен диңгездә,
Йөрсен корыда;

Кирәк вакытта
Оча да белсен,
Җир астына да
Ул үтеп керсен;

Бара алсын ул,
Кушсаң, кая да —
Менсен Марска да,
Очсын айга да...

Һәм ясый Сабит
Шуны хыялда.
Хыялда аңа
Соклана бар да:

— Бигрәк тә башлы
Бу Сабит, — диләр. —
Нинди машина
Ясый бит! — диләр.

Яки таба ул
Шундый бер дару —
Каршы торалмый
Аңа бер авыру.



Ютәлме, ракмы
Яки кычумы —
Бетә барсы да
Кабуга шуны.

Барлык докторлар
Гаҗәпкә кала.
Киләләр бар да
Ялынып аңа:

— Өйрәт безне дә,
Сабит дус, — диләр. —
Бу бит тиңдәшсез
Зур ачыш, — диләр.

Яки үстерә
Ул шундый бодай, —
Һәрбер бөртеге
Кечрәк кавындай.

Юк аны урып,
Сугып торасы,
Хәтта он итеп
Юк тарттырасы.

Тик үстер, төрле
Формага салып.
Көт өлгергәнен
Һәм аша алып!

Сабит турында
Тагын сөйлиләр:
— Вәт нинди бодай
Тапкан ул! — диләр. —

Чәчсәң мең гектар
Әгәр дә аны,
Тутырыр, — диләр, —
Бөтен дөньяны!..

Булган хыялны
Аның башында
Сөйләп бетереп
Булмас барсын да.

Ул хыялларның
Тик иң татлысы
Була һәрвакыт
Иң азаккысы:

— Эшләгән ул, — дип, —
Шундый зур эшләр,
Казанган ул, — дип, —
Шундый уңышлар, —

Сөйлиләр мактап
Бар җирдә аны.
Тарала аның
Дөньяга даны.

Җир йөзендәге
Барлык галимнәр
Иң зур галим, дип,
Аны саныйлар.

Ачыла аңа
Бөтен җирдә юл:
Булә профессор,
Академик ул...

Белмәгән өчен
Юньләп дәресен,
Гел «2» дә «3»
Алуы өчен

Класста Сабиттан
Көлгән балалар
Бар да кызыгып
Карыйлар аңар:

— Нишләде әнә,
Күр, Сабит! — диләр. —
Көлгәнбез аннан
Юкка бит! — диләр.

Гел «2» куйган
Укытучылар,
Классында калыр,
Дип куркучылар:

— Ялгышканбыз бит
Никадәр! — диеп,
Йөриләр бар да
Башларын иеп.


Кинәт шундый хәл
Була тагын да:
Алар үкенеп
Йөргән чагында,

Чыгара Указ
Верховный Совет:
«Дүртенче класста
Укучы Сабит

Күп еллар буе
Куеп бар көчен
Җибәргән өчен
Алга фән эшен —

Барлык укудан
Ителсен азат.
Йөреп мәктәпкә,
Чикмәсен азап!..»

Укый Указны
Әти-энисе,
Күзеннән яшьләр
Түгә әбисе:





— Юкка балакай, —
Ди алар бар да, —
Чиккән бит азап
Безнең аркада.

Мескенгә юкка
Тынгы бирмәдек;
Укымыйсың дип,
Көн-төн тиргәдек.

Ит, дидек, болай,
Ит, дидек, алай!
Ә бит булган ул
Шундый шәп малай!..

Ә Сабит йөри
Борынын чөеп:
— Кем булды менә
Абзагыз! — диеп.

Һәм юкка үзен
Йөдәткән өчен
Инде барсыннан
Ала ул үчен...

---

Өзеп әкиятне
Шушы урында,
Сөйләшик бераз
Хыял турында:

Кирәк нәрсә ул
Хыял, чыннан да.
Булмый хыялсыз
Яшәп дөньяда.

Хыял — кешене
Алга илтә ул.
Хыял — кешене
Кеше итә ул.

Ансыз үсеш тә,
Җиңү дә булмый.
Ансыз дөньяда
Бер эш тә тумый.

Тумый хыялсыз
Вак эш тә хәтта.
Ә бөек эшләр
Тумый бигрәк тә.


Никадәр кыю
Булмасын әнә,
Тырышсаң, хыял
Чынга әйләнә.

Ашыру өчен
Тик аны чынга,
Иренми бер дә
Кирәк укырга.

Укып күп нәрсә
Кирәк белергә,
Бик күп фәннәрне
Үзләштерергә.

Сез дә, балалар,
Хыялланыгыз,
Хыялны җигеп,
Алга барыгыз.

Тик бу киңәшне
Дөрес аңлагыз:
Сабит күк, бушка
Хыялланмагыз!



**АУЧЫ**

*(Кытай мәзәге)*

Булган бер аучы,
Җәнлек аулаучы.

Гомер буена
Йөргән ул ауга,
Чыккан кырларга,
Барган урманга.

Начар булганмы
Ләкин мылтыгы,
Сәбәп булганмы
Бәхет юклыгы,

Әллә бик начар
Күргәнме күзе,
Әллә сәләтсез
Булганмы үзе, —

Атса да төбәп
Нинди җәнлеккә,
Киткән ядрәсе
Һәрвакыт читкә.

Йөри торгач ул
Шулай, бер заман



Семьясы аның
Ач калган тәмам.

Биреп мылтыгын
Беркөнне аңа,
Әйткән хатыны:
— Бар әнә ауга!

Кайтмасаң ләкин
Берни дә атып,
Бу мылтыгыңны
Ташлыйм мин ватып!..

Ауга дип, тагын
Киткән ул, мескен.
Бар җирне айкап
Йөргән ул өч көн.

Начар булганмы
Ләкин мылтыгы,
Сәбәп булганмы
Бәхет юклыгы,

Әллә бик начар
Күргәнме күзе,
Әллә сәләтсез
Булганмы үзе, —

Атса да төбәп
Нинди җәнлеккә,
Киткән ядрәсе
Һаман да читкә.

Моңаеп кына
Кайтып килгәндә,
Күргән: авылга
Якын-тирәдә

Бер төркем малай,
Бәйләп муеннан,
Алып баралар
Аксак бер куян.

Шулар янына
Киткән аучыбыз.
— Куянны, — дигән, —
Миңа сатыгыз!

Бик риза булып
Малайлар моңа,
Аксак куянны
Сатканнар аңа.

Тотып куянны
Башыннан җайлап,
Куйган аучыбыз
Агачка бәйләп.

Янәсе, хатын
Эшне сизмәсен:
— Ник юк ярасы
Моның? — димәсен.

Һәм ул мылтыгын
Төбәп куянга,
Атып җибәргән
«Шарт!» итеп аңа.

Начар булганмы
Ләкин мылтыгы,
Сәбәп булганмы
Бәхет юклыгы,

Әллә бик начар
Күргәнме күзе,

Әллә сәләтсез
Булганмы үзе, —

Атса да, мескен,
Төбәп куянга,
Эләккән ядрәсе
Бәйләгән бауга.

Өзелгән дә бау,
Шунда ук куян,
Йөгереп китеп,
Күздән юк булган.

Шуннан соң аучы
Авылга кайтып,
Чәчүлек алган,
Мылтыкны сатып.

— Димәк, мин, — дигән, —
Бик начар аучы.

Аңламаганмын
Шуны моңарчы.


Алдап үземне,
Ник газап чигәм?
Ташлыйм бу ауны,
Гел иген игәм!..

Алыштырган ул
Шулай һөнәрен
Һәм тук үткәргән
Калган көннәрен.

* * *

Болай дип, дускай,
Аңла син моны:
Кулдан ни килсә,
Эшлә тик шуны!





## ТАШБАКА

*(Поляк халык әкияте буенча)*

Ташбаканың карчыгы
Чакыра кунак,
Бик шәп бәлеш пешереп,
Сыйларга уйлап.

Тик ул бәлеш ясарга
Тотыныйм дисә,
Чүпрәсе беткәнлеге
Исенә төшә.

Уята ул шуннан соң
Үзенең картын:

— Җитәр, — ди, — мич башында
Күп аунап яттың!

Тор да тизрәк, кибеткә
Йөгереп барып кайт.
Миңа бәлеш ясарга
Чүпрә алып кайт!..

Йокысыннан Ташбака
Көчкә уяна.

…зе уа күзләрен
Һәм мыгырдана:

— Беләсең бит, карчык, —
ди, —
Беркайчан да мин
Малай-салай шикелле
Йөгереп йөрмим.

Ә инде кирәк икән
Барып кайтырга,
Анысын мин булдырам,
Тик ашыктырма.

Кабаланмый эшләргә
Кирәк һәр эшне.
Ашка пешкән, диләр бит,
Ашыккан кеше!..

Шулай дип ул сөйләнеп
Төшеп җиткәнче,
Өстен-башын акрынлап
Киенеп беткәнче,

Сизелмичә бер сәгать
Үтеп тә китә.
Ә карчыгы ашыга,
Сабыры бетә:

— Тагын нәрсә кыймылдый,
Һәй, бу имгәк! — ди. —
Вакыт бик аз калды бит,
Булчы тизрәк! — ди.

Кирәк бәлеш ясарга,
Ягарга мичкә.
Болай да бит эшем күп, —
Өлгерәм кичкә!..

— Китермә әле, — ди ире, —
Юкка ачуны!
Югалган бит билбавым,
Эзлим ич шуны!..

Икәү эзләп тапканчы
Аның билбавын,
Үтеп китә, сизелми,
Бер сәгать тагын.

Билбау урап биленә,
Күтәреп яка,
Чыгып китә, ниһаять,
Өйдән Ташбака.

Ә карчыгы кычкыра:
— Эх син, аңгыра!
Алмагансың ич чүлмәк
Чүпрә салырга!

Алар өйдән чыкканчы
Чүлмәкне табып,
Үтеп китә тагын да
Бер сәгать вакыт.

— Җәтрәк йөр, — ди карчыгы,
Озатып аны. —
Килеп җитәр кунаклар,
Вакыт аз калды.

Очып бар да очып кайт,
Тукталып торма!..
— Беләм инде, — ди карты, —
Башны катырма!..

Чүпрә кайтып җиткәнче
Тик тормас өчен,
Куя карчык әзерләп
Бәлешнең эчен.



Әзер торсын мичем дә
Ягарга, диеп,
Мичкә коры утын да
Куя ул өеп.

Самовар да кайнатып
Куя шулай ук...
Ә Ташбака күренми,
Һаман юк та юк!

Көтә хатын бер сәгать,
Биш сәгать көтә...
Ул арада кунаклар
Җыелып бетә.

Килә Куян иң алдан,
Аннары — Төлке.
Кереп җитә, кыштырдап,
Күршесе — Керпе.

Ул керүгә бер сәгать
Үтте дигәндә,
Килеп җитә, шуышып,
Әкәм-төкәм дә.

Ә Ташбака юк та юк,
Һаман күренми.
Утыралар кунаклар,
Нишләргә белми...

Шулай аның кайтканын
Бик озак көткәч,
Үтеп көзге озын кич,
Кара төн җиткәч,

Инде артык көтүдән
Чыкмас, диеп, эш,
Кайтып китә кунаклар,
Ашамый бәлеш.

Хатын иренең кайтканын
Төн буе көтә.
Көтә торгач үзе дә
Йокыга китә.

Кайтмый ләкин Ташбака
Иртәгесен дә.
Үтеп китә шулай ук
Өченче көн дә.

Дүртенче көн дигәндә,
Хатын, борчылып,
Карап кермәкче була,
Өеннән чыгып.

Тик чыгуга ишектән,
Ябынып шәлен,
Күрә чаттан иренең
Кайтып килгәнен.

Чүпрә салган чүлмәкне
Куенга тыгып,
Кайтып килә, ди, теге
Шундый ашыгып, —

Аяклары бөтенләй
Тими, ди, җиргә,
Үзе, мескен, баткан, ди,
Шабыртма тиргә...

Үтмәгәндер бер сәгать
Күренүенә,
Килеп җитә Ташбака
Ишек төбенә.

Һәм туктап та тормыйча,
Шул кайткан көйгә,
Кереп китмәкче була
Тиз генә өйгә.

Тик бусага аркылы
Атлыйм дигәндә,
Абына да «шап!» итеп
Ава идәнгә.

Кулындагы чүлмәге
Тәгәрәп китә,
Чүлмәктәге чүпрәсе
Түгелеп бетә.

— Эх, имгәк, — ди хатыны, —
Дүрт тәүлек йөреп
Алып кайткан чүпрәңне
Бетердең түгеп!..

Әйтә шунда Ташбака,
Җилкәсен кашып:
— Ашыктырма дип сиңа
Әйттем мин, карчык!

Ә син минем әйткәнгә
Салмадың колак:
«Җәтрәк бул!» да «җәтрәк!»
дип
Тордың мыгырдап.

Каушаттың бит, җитмәсә,
Каршы ук чыгып.
Менә шулай була ул
Йөрсәң ашыгып!..





## ЯРЛЫ ҖИРЕ

*(Поляк халык әкияте буенча)*

Пан янына барган ярлы
Сорарга үгез:
— Зинһар, — дигән, — тик бер
көнгә
Биреп торыгыз!

Кич җитүгә кайтарырмын
Мин аны кире.
Юкса, минем үгез юк бит
Сөрергә җирне!..

— Ярый, — дигән пан, — тыңлыйм
мин
Бу үтенечең.
Тик бер капчык он түләрсең
Син моның өчен!


Ни эшләсен? Мескен ярлы
Күнгән бу сүзгә:
— Ярар, — дигән, — ашлык ургач,
Түләрмен көзгә...

Һәм киткән ул пан үгезен
Җигеп арбага:
«Ләкин ничек түләрмен, дип,
Онны мин аңа?..»

Тик авылдан ерак булган
Ярлының җире.
Ашыккан ул кичкә кадәр
Кайтырга кире.

Ә үгезнең, мәгълүм инде,
Адымы — салмак...





Барып җиткән кырга алар
Төш җиткәч, чак-чак.

Салып ташлап бик тиз генә
Чикмәнен җиргә,
Керешмәкче булган ярлы
Җирен сөрергә.

Җиккән теге үгезне дә
Сукага тиз-тиз,
Бетерергә уйлап эшне
Җиткәнчегә кич.

Ләкин... Бу ни?.. Аптырап ул
Як-якка карый:





Гомер буе сөргән җирен
Кырдан табалмый!

«Нәрсә бу, ди, әллә җеннәр
Буамы күзем?
Килдем мәллә бүтән кырга,
Ялгышып, үзем?»

Тагын карый як-ягына —
Ялгышмаган, юк!
Шул ук урман уң ягында,
Курган да шул ук!

Күршеләрнең җире менә!
Пан җире әнә!..
Баскан җирдә мескен ярлы
Зыр-зыр әйләнә.

Башын кашый аптырагач:
«Әле генә тик
Үз аягым белән басып
Торган идем бит!

Бу ни гаҗәп? Шул арада
Киткән ул кая?..»
Әйләнә торгач мескенкәй
Хәлдән үк тая.

Ә бит вакыт һаман үтә,
Анарга тизрәк
Үгезне панга кайтарып
Бирергә кирәк!

Карап-карап табылмагач
Үзенең җире,
Карар бирә бүгенгә ул
Кайтырга кире.

«Килермен, ди, иртәгесен
Күршеләр белән...»
Шулай дип ул кулга алса
Чикмәнен җирдән,

Кычкырып җибәрә кинәт
Шатлануыннан:
Аның җире чикмән белән
Капланган булган!

— Ә мин, ди ул, кайтырга ук
Җыенам, тиле!..
Шундый нәни булган элек
Ярлының җире!

———